Республика Татарстан
**СОВЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ахмадиева, д.26, п. Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК СОВЕТЫ**

Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы,423368
Телефон: (85559) 31-0-97,60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

**РЕШЕНИЕ**
**08.04.2016 ел**

**КАРАР**
**№26**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 137 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында»

«Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 431-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә Сарман районы прокурорының 2016 елның 29 гыйнварындагы №02-07-01/2016 протестын карап тикшерү буенча, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 20.11.2014 ел, №137 карары белән расланган «Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары турында белешмәләр бирү хакында» Нигезләмәнең 6 статьясындагы «в» пунктын, 13

статьясын үзгәртергә. «Килешү суммасы» гыйбарәсен «мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы»на алмаштырып үзгәртергә.

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе Л.М.Бадиков